ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЕЛАБУГА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 10 «07» 05 2019 ел.

Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитетының «2017-2020 елларга Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җирләү урыннарын карап тоту буенча муниципаль программа раслау турында» 2017 елның 31 октябрендәге 22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы һәм «Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турында» 2015 елның 22 октябрендәге 184 номерлы Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитетының «2017-2020 елларга Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җирләү урыннарын карап тоту буенча муниципаль программа раслау турында» 2017 елның 31 октябрендәге 22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарның аталышын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җирләү урыннарын карап тоту буенча муниципаль программа раслау турында».

2. 2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җирләү урыннарын карап тоту буенча муниципаль программаны кушымтага туры китереп, яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Садыйкова Э. И.) агымдагы финанслау хисабыннан 2019 елга Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җирләү урыннарын карап тоту буенча муниципаль программа чараларын үтәү өчен бюджет ассигнованиеләрен күздә тотуны киңәш итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны өчен үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче К.В. Мокшин